# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлегенең Рангазар авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**12 ноябрь 2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:
- Рангазар авылларында урамнарны яктырту, яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;
- Беларус-320.4 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Рангазар авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-Рангазар авыл зиаратында биек агачларны кисүгә( килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылында биек агачларны кисүгә (килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылының киров урамына шлагбаум үзерләү һәм урнаштыру өчен.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 249 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 167 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 167 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Рангазар авыл жирлегенең Рангазар авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2021 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:
- Рангазар авылларында урамнарны яктырту, яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;

- Беларус-320.4 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Рангазар авылларында  кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-Рангазар авыл зиаратында биек агачларны кисүгә( килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылында биек агачларны кисүгә (килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылының киров урамына шлагбаум үзерләү һәм урнаштыру өчен.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Рангазар авыл җирлегенең Рангазар мәгълүмати стендларына  урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче А.Р.Шарипова